# КАРАР

**29 ноябрь, 2021 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

« I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан) , Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1450 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Нократ Аланы-Малмыж трассасыннан Чуллы авылына кадәр килү юлына асфальт һәм вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Чуллы авылы Хажи Закиров урамы буенча юлларга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру»?
- Чуллы авылының урам юл челтәрен карап тоту, чапкыч һәм ягулык-майлау материаллары, запас частьлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 148 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 84 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 84 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан) , Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1550 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Чуллы авылына керу юлы борылышыннан Хаҗи Закиров урамы 52 нче йортка кадәр юлга вак таш җәю һәм ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү, проект-смета документларына экспертиза ясау һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Чуллы авылы Хаҗи Закиров урамы буенча юлларга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру»?
- Чуллы авылының урам юл челтәрен карап тоту, чапкыч һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Гарипов